ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 496-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 496-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 2 ноябре
№ 2222-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
Социаль сәясәт
комитеты тарафыннан
кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $11^1$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $13^4$ пункт өстәргә:

«$13^4$) ел саен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеге торышы турында доклад тапшыру;»;

2) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле $16^6$ пункт өстәргә:

«$16^6$) Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеге торышы турында еллык доклад әзерләүне һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында урнаштыруны гамәлгә ашыру;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасында парламент контроле турында» 2016 елның 12 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы нигезендә парламент контроле рәвешләренең берсе булып Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге нәтиҗәләре турында еллык хисапларны тыңлау тора.

Моңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеге торышы турында еллык доклад әзерләүне һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан аны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тапшыруны карау тәкъдим ителә.

Тәкъдим ителә торган үзгәрешләр сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын тәэмин итү һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының хезмәттәшлеге механизмнарын камилләштерү юлында мөһим адым булып тора.

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.